Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы
# Мәктәп пульсы



№3
Ноябрь
Декабрь 2018 г.

## С Новым 2019 годом!



***Дорогие учителя и ученики!***

Примите самые искренние поздравления с Новым годом! Желем вам крепкого здоровья, огромного личного счастья, благополучия, неиссякаемой энергии, реализации всех планов!

Пусть в Новом году вам неизменно сопутствует успех. Пусть вашим лучшим начинаниям всегда сопутствует творческое вдохновение и созидательная инициатива, а ваша энергия и смекалка служат залогом успешного выполнения намеченных планов.

Хочется пожелать вам, чтобы вы всегда были окружены теплом и любовью своих близких, уважением коллег и друзей, а отличное настроение и душевный подъем всегда сопровождали вашу жизнь!

Любви, добра и благополучия!

*С уважением,*
*редколлегия газеты!*

## Интересно знать!

- Каждый четвертый год считается **високосным годом.**
- Великий Устюг считается **родиной Деда Мороза.**
- 18 ноября — официальный **день рождения Деда Мороза.**
- В старину Дед Мороз **получал подарки от людей.**
- В середине двадцатого века родилась **внучка Дела Мороза.**
- **Эвкалипт** – новогоднее дерево в Южном полушарии.

## Что обещает Новый год?

***Символ 2019 года - Желтая Земляная Свинья. Что же ждет нас в новом году?***

Новый 2019 год свиньи будет благополучным для представителей всех знаков зодиака. Земляной Кабан любит искренние чувства, чаще всего дарит свое расположение веселящимся людям. Большинство новогодних примет на 2019 год связаны с его символом: это значит нужно делать все возможное, чтобы вызвать расположение покровителя года.

События будет много. Ожидать следует как хорошего, так и плохого. Считается, что Свинья, завершающая цикл восточного гороскопа, собирает все то, что ее предшественники не успели. Событий ожидается много, эмоциональная окраска их будет раз-



личной.

В 2019 следует завершить дела, начатые ранее. Новые начинания вряд ли станут удачными. Если все же вы планируете начать новый проект, делать это лучше в первые месяцы. Астрологи рекомендуют подождать до 2020, когда энергия Крысы будет благоволить к начинаниям и нововведениям.

## В этом выпуске:

Стажировка по туризму 2
Мәрхәмәтлек икеләтә, өчләтә артты 4
Туган як 5
Международный конкурс «Илхамят» 5
Көләч егетне Арчада кызлар ошатты 6
Вакыйгалар казанында 6

# Стажировка по спортивному туризму

***Недавно в Арском районе, а именно на базе Арского Дворца школьников, была проведена стажировка по программе организации и проведении занятий в учреждениях дополнительного образования по спортивному туризму для детей, обучающихся в разновозрастных группах.***

Данное мероприятие проводилось не первый раз, однако гостей было много, и все были из разных районов и городов Татарстана. Было проведено много полезных и разных мастер-классов. Возможности спортивного зала при проведении тренировочных занятий показали Ф.Ф. Минхаиров и Л.Я.Сафин педагоги Арского Дворца школьников. Методами работы на этапе «параллельные перила» ознакомил Р.В.Таушева из Набережных Челнов . Занятие спортивным туризмом в природных условиях показали педагоги Дворца школьников Р.Р. Набиуллин, И.Х. Шакиров, И.И. Залялиев, Ф.Ф. Нагимов. Гости перенимали опыт друг у друга. А также были показаны физические навыки и умения детей в этом направлении. Дети, посещающие кружок,



прекрасно показали то, чему они научились практически за год, ведь кружок был открыт еще только в ноябре того года. Некоторые волновались, но все же перебороли свой страх и вызвали у всех эмоции восхищения. Гибкие и умелые ребята сделали все, чтобы показать любовь к данному виду спорта. Профессионально оборудованный спортзал, тоже дал знать о себе.

- Мне очень нравится данный вид спорта. Если раньше я не знала куда деть свою энергию, то теперь знаю. Мы показываем очень хорошие результаты в районе и в республике. И все это благодаря нашему замечательному тренеру Минхаирову Фариту Фатхиевичу, который постоянно нас поддерживает. Я хочу связать свою жизнь именно со спортивным туризмом, а пока я тренируюсь и учусь основным его приемам, - сказала Диля Харисова ученица секции спортивного туризма Арского Дворца школьников.

День был солнечным, и благодаря этому ребята смогли показать свои навыки также на новом, построенном Дворцом школьников, тренировочном полигоне, в условиях дикой природы.Гости были удивлены такому полигону, так как не везде имеются данного типа базы. Итак, каждый участник стажировки получил для себя новые и в то же время полезные информации от своих коллег. Педагогический коллектив Дворца школьников сделал все возможное .чтобы этот день стал уникальным и запоминающимся надолго.

**Ляйсан САФИНА,**
*член клуба юных журналистов «Тукай якташы»*

# Туристлар өчен стажировка

***4 нче октябрь көнне Арча Укучылар Сараенда туризм секцияләрен җитәкләгән республика педагоглары өчен стажировка үтте. Бик күп осталык дәресләре һәм күрсәтмә чыгышлар уздырылды.***

Мәсәлән, “Акыл картасыуңышка юл’’дигән проект оештырганда нинди кагыйдәләрне һәм шартларны истә тотарга кирәк икәнен сөйләделәр. Укучылар Сарае педагоглары Ф.Ф.Минхаиров һәм Л.Я. Сафин спортзалда туризм белән шөгыльләнеп булганнын күрсәтә торган осталык дәресен үткәрделәр. Шулай ук Яр Чаллы шәһәреннән килгән тренерлар да үзенең тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

Беренче булып яңача ысуллар белән страховочный системалар кияргә икәнен И.В.Галимуллин өйрәтте. Икенче булып үзенең осталыгын Р.В.Таушева күрсәтте. Ул парралелельный перилада дистанцион һәм пешеход связка белән йөрү ысуллары турында сөйләде. Стажировка барышында яшь туристлар да чыгыш ясады. Алар төрле сынаулар үттеләр: бау белән эшләделәр,палатка куйдылар , бүрәнәләр аша үттеләр.

*Дәвамы киләсе биттә...*

# С высоким званием Вас, учитель мой!

***Заместителю директора по воспитательной работе нашей Лесхозской общеобразовательной школы Арского района Гайнановой Фирае Накиповне присвоили высокое звание нашей республики «Заслуженный учитель Республики Татарстан».***

Фирая Накиповна - это учитель который всю свою жизнь отдала детям, педагог помогающий ученикам в их начинаниях и поддерживающий во всём. За чтобы она не бралась, доводит своё дело до конца, тем самым приносит нашей школе большие успехи. И сегодня мы у неё в гостях.

**- Фирая Накиповна, когда у вас появилось желание стать учителем?**

- Это у меня давнишняя мечта, уже до школы я мечтала об этом. В детстве, когда у нас не было ещё тетрадей, я собирала лопухи и играла, будто я учитель, а мой братишка, который был на два года младше - ученик.

**- Как вы учились в школе?**

- Я училась хорошо, девять классов Лесхозской восьмилетней школы окончила только на отлично. Нашим классным руководителем была Раиса Максумовна. . В классе нас было 23 учащихся - из них 7 девочек и 16 мальчиков. Наши девочки были лидерами класса. В моей школьной жизни было очень много веселых и увлекательных историй, все не перечесть. Мы любили устраивать классные огоньки, концерты, комсомольские собрания, праздничные мероприятия, посвященные различным датам.

**- Сколько лет вы работаете в нашей школе?**

- Мой педагогический стаж составляет 31 год. Начала свою педагогическую деятельность в 1980 году в СПТУ номер 9 учителем математики, прора-ботала там 7 лет .А в 1987 году начала работать в нашей школе учителем математики и пионервожатой. В1993году школа стала средней, и меня назначили заместителем директора по воспитательной работе.



**- О чём вы думали,когда шли на первый урок?**

- Это был третий курс и моя первая педагогическая практика прошла в 133 школе города Казани. Тогда работал очень строгий завуч Мурзин, он и сам был учителем математики. Урок я дала в седьмом классе, где было 37 учащихся. И во время урока у меня упала линейка и тогда этот завуч мне сказал: «Что ты глазастая, испугалась».

**- Что вам нравится и не нравится в вашей работе?**

- Я люблю свою работу, учеников, учителей. Если я дома то все равно все мысли только о школе .В школу иду и думаю, о детях - чтоб они были здоровы, на работе все было хорошо, а когда возвращаюсь - с мыслями о том, что я выполнила свою работу и спокойно иду домой. Единственное, что мне не нравится это то, что дают слишком много бумажных работ.

**- Чем вы любите заниматься дома?**

- Дома я очень люблю заниматься чтением. И бывает, что самое большее количество периодической печати получаю я. И ещё люблю выращивать цветы: домашние и садовые.

Фирая Накиповна, Вам присвоили это высокое звание, значит, Вас уважают и оценивают. От всей души поздравляем Вас. Большое спасибо, что нашли время и ответили на мои вопросы.

**Адиля ГАЛИМЗЯНОВА,**
*журналист*
*Арской телестудии «Нур»*

# Туристлар өчен стажировка

....Аннары килгән кунаклар өчен туристик полигон белән таныштыру булды. Полигон Арча Укучылар Сарае хезмәте һәм мөмкинлеге белән төзелгән. Анда башка авыллардан һәм башка районнардан килгән балалар стажировка үткән туристларга үз осталыкларын күрсәтте. Программа ахырында табигый шартларда туризм белән шөгыльләнергә мөмкин икәнен күрсәттеләр. Иң мөһиме тырышлык һәм теләк..Бу чара бик кызык һәм файдалы узды.

**Зөһрә АРСАЕВА ,**
*Арча Укучылар Сарае*
*"Тукай якташы"*
*яшь журналистлар клубы*

# Мәрхәмәтлекне болай гына өләшәм!

***24нче ноябрь көнне безнең мәктәптә Илья Гарасов исемле җырчы, талантлы алып баручы, режиссер, сценарист, гомумән искиткеч сәләтле егет чыгыш ясады.***

Башта укучылар арасында кызысыну сизелмәде, әмма җырның беренче аккордларыннан соң артист аларның игътибарын үзенә җәлеп итте. Тамашачылар күп булу сәбәпле, Илья программасын ике тапкыр күрсәтергә булды. Аның сүзләренчә: “Сезнең дустанә мөнәсәбәтегез мине ардырмый, көч-куәт өсти!” Аның белән якыннанрак танышыр өчен, без кыскача әңгәмә уздырдык:

**- Илья, үзегез турында сөйләп китегез әле.**

- Мин 19 яшьлек Казан егете. Филология белән кызыксыну мине Казан Федераль Университетының икенче курсына китерде. Кечкенә чактан ук җырларага, биергә, рәсемнәр ясарга яратам.

**- Ә җыр сәнгате белән филология арасында нинди уртаклык бар?**

- Минемчә, кеше төрле яклап үсәргә тиеш, шуңа күрә кулга килгәннең барсын да эшләргә тырышам.

**- Безнең мәктәпкә килүегезнең сәбәбе нидә?**

- Кешеләргә ярдәм итү – минем максатым. Сезнең мәктәбегез, минем уйлавымча, иң матур, чиста, тәртипле. Шуңа күрә Арчаның кайсы мәктәбенә килү мәсьәләсе безне озак борчымады.

**- Программагыз турында сөйләп җибәрегез әле.**

- Минем программалар беркайчан да кабатланмый. Төрле яшьтәге тамашачы өчен үзенчәлекле итеп тәкъдим итәргә тырышам. Һәрбер кеше, минем тамашага килгәч, үзенә рухи азык ала, рәхәтләнеп күңел ача алсын иде. Программа өч бүлектән тора: моңсуландыра, тынычландыра һәм яхшылыкка өнди. Беренче һәм өченче бүлек каверлардан торса, 2нче бүлек үземнең иҗат җимешләремнән оеша. Шигырьләр... Алар күңелемне илһамландыралар, көч өстиләр.

**- Укучыларга дәртле татарча җырлар нык тәэсир итте. Әйтегез әле, татар телен өйрәнергә читен булмадымы?**

- Оо, йокламаган төннәр, уйнамаган кичләр хәйран булды... Ләкин мин татар телен белергә кирәк дип саныйм. Ничек инде Татарстанда яшәп, татар телен белмәскә?



Котычкыч хәл бит бу! Сезне дә, дуслар, туган телне өйрәнергә өндим. Бары тик туган телне, туган илне яратканнардан гына җәмгыятькә яраклы кешеләр туыр.

Шулай итеп, без кадерле кунагыбызны озатып җибәрдек. Мәктәбебез укучылары турында да әйтәсебез килә! Дуслар, сезнең көчле алкышларыгыз, чын күңелдән елмаюларыгыз Ильяны гына түгел, барыбызны да дулкынландырды! Һаман шундый актив, тәртипле булыгыз!

**Гөлфинә ҖӘЛӘЛИЕВА,**
11нче сыйныф
**Рүзәл ШАРИПОВ,**
9Б сыйныфы

# Мәрхәмәтлек икеләтә, өчләтә артты

***Ансат юл белән байлык туплау нияте көчәйгән заманда, яшьләребез кайсы кыйблага табынырга тиеш? Әхлаксызлык, миһербансызлык чиреннән аларны ничек саклап калырга?***

Арчаның “Исток Надежды” мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәгендә, инвалидлар декадасы уңаеннан, “Игелек кыл!” исемле хәерия концерты үткәрелде. Тумыштан гарип булып, дөньяның рәхәтен күрергә тилмереп үскән балалар өчен зур бәйрәм ясалды. Сәхнә хуҗалары – Арчаның 2 нче мәктәбе укучылары. Шунысы куанычлы: яшьләребез ярдәмгә мохтаҗлар язмышына битараф түгел. Алар белән берлектә, ел саен, әлеге декада уңаеннан күп чаралар үткәрелә.

Быел да, тынгысыз йөрәкле укытучылары Лилия Жиһангирова, Алина Мөхәммәтгалиева, Динә Ибраһимова, Миләүшә Сәгыйтова белән бергәләп, бик матур, эчтәлекле чыгыш әзерләделәр. Һәрбер җан иясенә шәфкатьле булырга кирәклеген, әзерлек барышында, 30 укучы аңлады. Җырлап-биеп, яшьтәшләренең күңелен күтәреп, аралашып кайтканнан соң бу сан икеләтә, өчләтә артты. Кайткач сыйныфташлары, гаиләдәге туганнары белән сөйләшеп, рәхәтлекнең нигезе – мәрхәмәтлелектә икәнен аңларга булыштылар. Рәхмәт аларга.

**Рәсимә ИБРАЕВА,**
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

# Туган як

***Һәр кешенең күңелендә гомеренә саклана торган иң кадерле җире була. Бу җир - туган як. Туган як дигәндә, авыл яки шәһәр генә түгел, андагы кешеләр,әти-әни, һәрбер агач, кош та күз алдында.***



Һәр кеше, кайда гына булмасын, һәрвакыт туган ягын сагынып яши. Чөнки ул монда иң беренче адымын атлаган, сөртенә-сөртенә тәпи йөреп киткән, беренче тапкыр дөньяны шунда аңлаган. Туган ягының һәр җирен, кузен бәйләп җибәрсәләр дә ул белә,таный.Туган яктагы һәрбер агач, үлән, җанвар аңа таныш була.

Минем дә шундый җирем бар. Ул - Арча районы Субаш Аты авылы. Исеменнән үк куренгәнчә Аты елгасының башланган җирендә утыра. Шуңа күрә кайсы яктан гына килеп керсәң дә челтерәп аккан чишмәләр каршы ала. Авылымның кешеләре эшчән, тырыш. Матур хезмәтләре белән дан казанган язучылар Солтан Гыйлемханов, Рәис Сафин шушы авылдан. Авыр сугыш елларында, сугыштан соңгы чорда Субаш-Аты балалар йорты илгә танылган кешеләр тәрбияләп биргән.

Мин Арчада яшәсәм дә авылыма ашкынып кайтам. Анда сулар һавалар да икенче. Һәр кеше белән үз итеп, кул биреп күрешәм. Туган ягым үзенә һәрвакыт тартып тора....

**Ислам МИНҺАЖЕВ,**
5 Б сыйныфы

# Арча - минем туган илем!

***Минем Туган илем бик матур. Казанда тусам да Арча минем өчен яраткан як. Арча уртасында матур, күңел явын алырлык үзәк бар. Анда бик зур манара бар.***

Арча шәһәре уртасыннан Касансу елгасы ага. Безнең Арча шәһәре һәйкәлләр дә күп: әйтик, Г.Тукай, В.Ленин һәм башкалар.

2008 елда Арчага шәһәр статусы киредән кайтарыла. 2018 елда Арчада барлыгы 7 мәктәп, 1 чиркәу, 5 мәчет, зур хастаханә, бик күп даруха-нәләр, балалар бакчалары бар. Балалар бик яратып йөри торган боз сарае, бассейн бар. Казансу елгасы янында бик зур ял иту мәйданчыгы бар, аны «Казансу паркы» дип йөртә-ләр. Җәй айла-рында анда су коенып, ә кыш көне чана-да,чаң-гыда шуып була. Арча Казаннан төньяк-көнчы-гышка таба 65 км ераклыкта ур-нашкан. Арча шәһәренең башлыгы - Илшат Нуриев. Мин хәзерге вакытта Арчаның 2 номерлы мәктә-бендә 5 сыйныфта белем алам, миңа анада бик тә ошый. Без гаиләбез белән мәктәп янында зур йортта яшибез. Миңа



Туган ягым мин ошый,һәм мин аны бик нык яратам.

**Зәлия АЮПОВА,**
5 сыйныф

# Международный конкурс «Илхамят»



Недавно в городе Казани прошел Международный конкурс-фестиваль речевого и вокального искусства “Илхамият”, в котором приняли участие и ученики нашей школы.

**Мухаметгалиева Ралина** стала лауреатом 1 степени.

**Вокальный дуэт РозалИс** - стал лауреатом 2 степени. ***Поздравляем!***

# Вакыйгалар казанында

### *Баш әйләндергеч бармаклар*

Арча сәнгать мәктәбе укучылары Яшел Үзәндә узган «Баш әйләндергеч бармаклар» исемле халык уен коралларында уйнаучы яшь башкаручылар II Ботен-россия конкурс-фестива-лендэ катнашып жину яулап кайтты.

Безнең мәктәп укучысы Алмаз Әсәдуллин - 1нче дәрәҗә дипломант!



### Бердәм дәрес

Россия Конституциясе кабул ителүгә 25, Халык хокуклары гомуми декларациясенә 70 ел тулу уңаеннан Арчаның икенче мәктәбендә Бердәм дәрес үткәрелде.



Анда Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкиленең Арча районындагы җәмәгать ярдәмчесе Ринат Һидиятов катнашты. Ул 10 сыйныф укучылары алдында чыгыш ясап, республикада, районда кеше хокукларын саклау турында сөйләде, сорауларга җаваплар бирде.

# Көләч егетне Арчада кызлар ошатты

***КФУның 2нче курс студенты, гел елмаеп торучы җырчы егет 24 ноябрьдә Арчаның 2нче мәктәбендә көтеп алынган кунак иде.*** “Иртәнге 6да кайтып җитеп, шәһәрегезне карап йөрдем. Сездәге матурлыктан күңелем ял итте”, – дип каршы алды ул безне. Физик мөмкинлеге чикләнгән димәссең – күңеле көр, бик хәрәкәтчән.

Алып баручы, режиссер, сценарист, автор башкаручы егетне кызлар бигрәк тә үз иттеләр. Җырчының беренче аккордларыннан соң ук залдагы тынлык көчле кул чабулар белән алышынды. Ул тамашачыларының игътибарын шундый тиз үзенә җәлеп итте дә куйды. Илья сәгать ярым чыгыш ясаганда, хәтта елмаюы аша мәрхәмәтлек өләште.

Авыр операция кичергән Казан егете Илья Гарасов кешеләрне ярата, тормышта актылыкка омтыла. Язмышыннан зарланмый һәм сыкранмый гына шигырьләр, җыр текстлары иҗат итә. Ул шулай авырлыкларны җиңәргә үзендә көч таба. Тагын бер катлаулы операция көткән егет, ихтыяр көчен туплап, матурлыкны тудыра, үзенең җырларын халыкка бүләк итә.

– Программаны төрле яшьтәге тамашачы өчен дип әзерлим, – дип сөйләде ул. – Репертуарга дәртле җырлар белән бергә моңлы классик әсәрләр дә кертергә тырышам. Һәрбер кеше, минем тамашага килгәч, рәхәтләнеп күңел ача алсын. 2нче бүлек – тулысынча үземнең иҗат җимешләрем. Шигырьләремне сәхнәдән сөйләргә бик яратам. Алар күңелемне илһамландыра, яшәргә көч бирә. Беләсезме дусларым, һәр аралашу миңа көч-куәт өсти.

Рус милләтеннән булса да, укучыларга дәртле татарча җырлар бүләк итте Илья. Гаҗәпләнеп сору бирүчеләргә: “Йокламаган төннәр хәйран булса да, теләк булганда телне өйрәнеп була. Мин татар телен белергә кирәк дип саныйм. Ничек инде Татарстанда яшәп, әлеге аһәңле, матур яңгыраш-лы телне белмәскә?!” – диде ул тагын да бик мөлаем елмаеп.

Операцияне җиңел күтәреп, сәламәтләнеп, концерт залларында тамашачылар белән кабат очрашырга язсын сиңа, Илья!

**Рәсимә ИБРАЕВА,**
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Дизайнер - верстальщик*** Рузаль Шарипов
***Фотокорреспондент*** Диана Галимова
***Корректор*** Данил Степанов
***Редколлегия*** Алия Хабирова
***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15
***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2